Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110


Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АВГУСТ * 2024 * КАЗАН

8

Ринат АБЗАЛОВ



– Тиздән без кыйммәтле фатирда яшәячәкбез!
– Нәрсә, яңаны сатып алабызмы әллә?
– Юк, фатирга түләү бәясен күтәргәннәр...

Алмаз ХӘМЗИН

ЫШАНАСЫ КИЛӘ

1923 нче ел
Зур ил төзи Совет дәүләте
Матур яшәсен дип халкы гомергә
Матбугатны җигә куәтле!

Идеологиягә нигезләнгән
Җәмгыять тә китә көчәеп.
Чыга башлый газета-журналлар күп,
Кино карый кеше, кинәнеп.

Укымышлыкка юл тота дәүләт,
Индустриягә йөз-карашы,
Күмәк хуҗалык итүгә тартылган
Ул чактагы халык тормышы.

Кем эшләгән дип сез уйлыйсыз моны?
Җавап бирәм: "Көчле нәшрият!"
Дәүләт үзе тудырган барлык шартлар –
Бу хикмәткә булган барсы шат!

Шул исәптән, журналыбыз "Чаян" да
Яңарышның алгы сафында.
Үз ролен бик тә яхшы үтәгәнен
Беләбез нәшрият таңында.

Ул вакытта әдәбият намусын
Бик югары тоткан шәхесләр:
Такташлар, Кутуйлар, Җәлилләр,
Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмирләр, –
"Чаян"да бит эшли иделәр!..

Ә хәзер андыйлар юк инде, бетте.
Алар урынына калды бары:
"Халык язучылары", "шагыйрьләре" –
Хәзерчебезнең "классиклары"!

Язмыйлар берсе дә. Нигә соң ул алай?
Куркалар. Чөнки юк яклаучы.
Әхлаксыз, вөҗдансыз дөньяда
Бүген ни күргәнең ярамый түрәгә,
Кирәк тик яманнны лаклаучы.

Язалар вак-төяк чүп-чарны бик тә күп
Җәмгыятьтә бар да җитешме?
Атлаган саен абынам да сөртенәм,
Күз салсам оялам, диешле.

Бар әле хәзерге "классиклар"дан тышта
Тормышка аек караучылар.
Матур булсын дип киләчәктә дә яшәү
Чынлыкны чынлап язучылар!

Бар инде кайбер даирәләрдә дә
Якты чагылышның яктысы.
Үзгәрәсе дөнья беленеп тора
Чөнки җиттек чиккә, ахрысы.

Көтәбез, күңел сизенә дә кебек,
Алданмабыз сыман мәңгегә...
"Башларыннан инде – Такташ әйтмешли, –
Коммунизм кыры күренә!"

Ай-һай, дустым, безгә әле син күргән
Бер өмет юк язмыш түрендә...



Александр АЛЁШИН

СӨЮ АРИФМЕТИКАСЫ

Миңа җитмеш.
Сиңа – егерме биш.
Кызыктырмый ләкин яшьлегең:
Кочалмамын чөнки йөз илледә
Хатын-кызның йөз биш яшьлеген!

ШАШКЫН ТӨННӘР

Аһ сез, шашкын
сөю тулы төннәр...
Тик яшь бара, калдым соңгарак...
Шуңа күрә якын күрәм төннең
Җәйгеләрен – алар кыскарак...

Ринат АБЗАЛОВ

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Күпме вакыт инде телефон мошенниклары һәм аларның ысуллары турында сөйләп, безнең колак итен ашыйлар, ә алар һаман халыкны алдый бирә. Ярый ла беркатлы пенсионерлар гына булса, аларның кармагына депутатлар, чиновниклар, эшмәкәрләр, хәтта хокук сакчылары да эләгә. Мәсәлән, күптән түгел Мәскәүдә бер судья ханым, аферистларның телефоннан шалтыратуларына ышанып, ике миллион сум акчасын «куркынычсыз счёт»ка күчергән.

Р. ХАЛИТОВ

ТҮБӘН КАМА

– Аның белән барысы да аңлашыла, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Ул телефоннан әйткән һәрнәрсәне башкарырга өйрәнгән бит.**

Александр БРЮХАНОВ

САУБУЛЛАШУ

– Әфәнделәр, безнең арабыздан әле яшәргә дә яшәргә тиешле, шат күңелле, якты кеше, коллективыбызның тәрәге китеп барды, – дип башлады сүзен, эш киемендәге ир кеше, эчеп куйганнан соң.

– Барыбызга да бик кызганыч, бертуктаусыз күз яшьләре ага. Безнең белән хәзер кем сөйләшер, матур сүзләрен әйтер һәм бер-ике рюмка йотып куяр... – әлеге сүзләрне алдагы ирнең дәвамы итеп, фетр эшләпәле өлкәнрәк абзый чәркәсен күтәреп куйды.

– Хуш, дустыбыз, күпме еллар бергә булдык, менә соңгы мизгел дә җитте... – диде егет кеше, кулындагы баш киемен йомарлап.

Чамадан тыш иренен куе итеп буяган хатынның күзләрендә яшь тамчылары ялтырады...

– Нәрсә, акылдан шаштыгызмы әллә, – дип, урыныннан сикереп торды нурлы күзләрен җемелдәтә-җемелдәтә бер ир-ат, – мине теге дөньяга озаткан кебек бу. Мин бит машина гына сатып алдым. Мин бит һаман сезнең белән...

– Ничек инде безнең белән? Син бит хәзер гаражлар, гаишниклар янында һәм автозаправкаларда йөрерсең, ә эчү мәсьәләсендә ләм-мим... Син безнең өчен югалган кеше... – дип әйтеп салды абзый кеше...

– Төрле-төрле кызлар ташырсың, "бомбить" итә башларсың, – диде теге эш киемендәге эшче...

– Без – җәяү йөрүчеләргә икенче төрле мөнәсәбәттә булырсың, ягъни сәлам дә бирмәссең, – дип кушылды ризасызлыкка егет кеше, баш киемен селтәп.

– Әйдәгез, эчеп куйыйк әле тагын бер мәртәбә – безне вакытсыз ташлап киткән өчен... – монысын чәркәсен чәкешеп ветеран карт әйтте...

– Ну-у сезне! – дип кенә әйтә алды ап-аек автомобиль хуҗасы һәм башын түбән иеп, боларны ташлап чыгып китте.

– Әгәр авария-фәләнгә эләксәң яки шундыйрак хәлләргә очрасаң, чүтеки кергәләп йөр, – дип, артыннан кычкырып калды әлеге дә баягы иренен тагын да калынрак итеп буяп утыручы хатын-кыз.



Валентин ДУБИНИН

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Синоптиклар, сапёрлар кебек, бер генә тапкыр ялгышалар. Ләкин көн саен.

Әгәр акча сезне бәхетле итә алмый икән, димәк, ул сезнеке түгел.

Гомер ике өлешкә бүленә – башта акыл җитми, аннан соң – сәламәтлек.

Тәмәке тарту зыянлы, аракы эчү тәмсез, ә сәламәт килеш ул үкенечле.

Ирләр бөтенесе дә бертөсле, хезмәт хаклары гына төрле.

Мәхәббәт – өйләнешү белән дәвалана торган вакытлыча акылдан язу.

Яхшы фикер тәҗрибәдән килә, ә тәҗрибә – ялгыш фикердән.

(Акыл ияләре мәҗлесендә язып алынды)



Игорь КИЙКО

Гамьсез җайдаклар

Тарих тагын юл башына әйләнеп кайтты бугай: автомобиль затлы әйбер булган заманалар килде. Һәм гасырлар тузаны кунган шома юлларда хәзер дүрт көпчәкле "карлыгачлар" түгел, ә күпкә арзанрак электр самокатлары, гироскутерлар һәм башка ике тәгәрмәчле хикмәтләр юл сала. Тагын шәһәр асфальтында гына түгел, ә сикәлтәле авыл юлларында да үзләрен иркен тоткан мотоцикллар заманы килде. Татарстанда аларның саны сизелерлек дәрәҗәдә артты. Бүген республика киңлекләрен 14 меңнән артык тимер ат айкый. Алар белән бергә яңа буын – нәни мотоциклларга атланган "питбайкер"лар буыны шытып чыкты. Тәҗрибә дигән нәрсәне белмәгән, юл кагыйдәләре белән таныш булмаган яшүсмерләр, үҗәтләнеп, хәвеф-хәтәр белән тулы зур юлга омтылалар.

Питбайкларга атланган балалар катнашы белән килеп чыккан юл-транспорт вакыйгаларының саны быелгы сезонда арткannан-арта бара. Арча районында өч яшь "мотоҗайдак", кичүдәге светофорда кызыл ут януга карамастан, йөк поездына юл бирмәгәннәр. Бәхеткә, ике 14 яшьлек йөртүче һәм пассажир исән калганнар, әмма барысына да хастаханәдә ятып чыгарга туры килгән. Тагын бер тизлек сөюче артта утырган иптәше белән Лаеш районында йөк машинасына барып бәрелгән. Башларында шлемнары булмау сәбәпле, алар каты җәрәхәтләнгәннәр. Ә Аксубай районында тугыз яшьлек үсмерне изелеп беткән кечкенә мотоциклы астыннан чыгарганнар. "Тимер ат"ның тизлеге шундый булган ки, ул җайдагына буйсынмый башлаган. Нәтиҗәдә – куллары һәм аяклары җәрәхәтләнгән, ә үзенең куркудан тешләре тешкә тими. Әмма тагын да күңелсезрәк вакыйгалар бар. Күптән түгел Алабугада бер егет югары тизлектә пассажирлар белән тулы "ПАЗик"ка килеп бәрелгән. Кызганыч, аны инде коткара алмаганнар...

Әгәр электр самокатлары һәм башка төрле "шәхси хәрәкәт итү чаралары" белән инде катгый кагыйдәләр һәм зур штрафлар ярдәмендә азмы-күпме тәртип урнаштырсалар, ике тәгәрмәчле нәни мотоцикл закон кысаларына бөтенләй кермичә калган – ул хәтта хәрәкәт итү чарасы булып та саналмый. Питбайкның фаралары, борылыш сигналлары, көзгеләре дә юк. Чөнки ул бездә гомергә дә булмаган махсус юллар өчен көйләнгән. Шуңа күрә ул гамьсез йөртүчеләр белән бернәрсә дә эшләп булмый. Инспекторлар алар артыннан куарга да теләмиләр – бәлки, малай актыгы качып китәргә теләр? Ә бу очракта эшнең нәрсә белән бетәсен беркем белми...

Әлегә бу мәсьәлә кече шәһәрләр, бистәләр һәм дача кооперативлары проблемасы, ләкин ул киңәйгәннән-киңәя бара. Һәм эш монда башсыз яшүсмерләрдә генә түгел, ә балаларына шундый бәлагә китерә торган уенчыклар алып бирүче ата-аналарында да. Бу өлкәдә тәрбияләү – тиз нәрсә түгел. Барысына да төрлечә барып җитә бит. Ә хәзергә яшь питбайкерлар өчен иң яхшысы – өлкән иптәшләренең яраткан әйтемен истә тоту: сәгать сигездә моргта булуың караганда, тугызда өйдә булуың хәерлерәк.

Людмила САФИУЛЛИНА



Александр АЛЁШИН

Игорь КИЙКО



Максим СМАГИН



Вячеслав ШИЛОВ





• • •

Электрон китаплар барлыкка килде, электрон акчалар, тәмәкеләр дә. Инде электрон аракы гына ясыйсы калды, бу очракта аның артыннан кибеткә йөгерәсе булмый, интернеттан гына суырту җае чыгар.

• • •

Безнең зур җитәкчебез урламый. Аның өчен урынбасарлары тырыша – урлыйлар, бүлешәләр һәм утыралар.

• • •

Безгә хезмәт хакын әйбәт түлиләр, хәтта җыеп та бара алабыз. Быел машинамның тәгәрмәчләрен кышка-җәйгә алыштырудан ваз кичтем, шулай ук теш табибына ел саен күренүне дә кичектердем.

• • •

– Сеңлем, кулыгызны сузыгыз, сезгә конфет бирәм!

– Әтиемә бирсәгез яхшырак булыр!

– Карале, нинди мәрхәмәтле кыз!

– Әтинең учы зуррак чөнки.

• • •

– Ишеттегезме, тиздән кәгазь китаплар чыгаруны тыячаклар?

– Ни өчен?

– Аларда реклама куеп булмый.

• • •

Урам буйлап ир белән хатын бара. Каршыларына чибәр кыз килә. Хатыны:

– Мөнә корсагыңны эчкә тартып кына кара! Үтерәм!

• • •

Петров берүзе генә була алмый. Ул һәрвакыт Ильф һәм Петров, Петров һәм Васечкин, Петров һәм Бәширов. Әгәр дә инде ул берүзе икән, ул чагында Петров-Водкин килеп чыга.

• • •

Табибның кабул итү бүлмәсендә:

– Авыру, эшегез бик тынгысызмы?

– Мин компьютерчы, доктор.

– Бик яхшы, интернет белән кыенлыклар минем.

– Ә сезгә хастаханәдә интернет нигә кирәк соң?

– Ә сезгә ничек итеп диагноз куйыйм, күгәрченем?

• • •

Пациент кыз:

– Доктор, башым авырта минем.

– Шулаймы, мин бит сездән бернәрсә дә таләп итмим.

• • •

Тиздән аракы бик нык кыйммәтләнәчәк, күбенгәнче эчеп, вокзал тирәсендә байлар гына аунап ятачак.



КҮЛӘГӘ МӘГАРИФ

ТР Дәүләт Советы депутатларының берсе көтелмәгән саннар китерде. Татарстанда мәктәп тәмамлаучыларның 70 проценты репетиторларга мөрәҗәгать итә икән. Нәтиҗәдә, республикада бик зур "күләгә базар" барлыкка килгән, һәм анда ел саен миллиард сум чамасы акча әйләнештә. Парламентарий фикеренчә, чын белем бирүне шулай итеп хезмәт күрсәтү алыштырып бара.

МОҢ-ЗАР РЕЙТИНГЫ

Татарстан Дәүләт торак инспекциясе Казанның идарәче компанияләре өстеннән язылган шикаятьләр санын җәмгыятькә җиткерде. Мәсәлән, Декабристлар урамындагы 129 нчы йортта яшәүче берәү 9 ел эчендә торак хуҗалыгына мең ярымнан артык гариза язган. Восстание урамындагы 84 нче йорттагы гаилә биш ел эчендә 673 тапкыр зарланган. Ә Парин урамындагы 10 нчы йортта яшәүче ханым бары тик 99 тапкыр гына мөрәҗәгать иткән. Коммуналь хезмәт оешмаларына 800 мең сум бурычы җыелуга карамастан. Фатир өчен ул инде 12 ел буе түләмәгән, чөнки газ, электр энергиясен һәм суны табигать үзе бирә дип саный икән.

ТӨРМӘ БИЗНЕСЫ

Яшел Үзән районының Карамалы Тау бистәсендә урнашкан 5 нче төзәтү колониясенең башлыгын һәм аның урынбасарын ришвәт алуда гаепліләр. Территориясендә кафе ачарга рөхсәт биреп, колония җитәкчелеге табыштан процент таләп иткән. Ел ярым эчендә аннан 755 мең сум "тамган". Өстәвенә, тикшерүчеләр хөкем ителгәннәрнең берсен "үз канаты астына" алган өчен зона хуҗасының 105 мең сумлык айфонга ия булганын ачыклаганнар.

УРЛАНГАН МИЛЛИОН

Сабадагы «Торак-коммуналь хуҗалыгының күптармаклы җитештерү предприятиесе» акционерлык җәмгыятенең директоры, түләмәүчеләр белән армый-талмый көрәшеп, оешманың бюджетын тулыландырган. Бу яхшы, әлбәттә, ләкин ул үз кесәсе турында да онытмаган. Ялган товар чеклары ясап, һәм хезмәткәрләренә үзенә кирәк кадәр аванс отчётлары ясаткан. Шулай итеп, үз йортының төзелешенә миллион сум акча керткән. Хәзер прокуратура «үзләштерелгән» сумманы район бюджетына кайтаруны таләп итә.



Герман ОГОРОДНИКОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ

Их, бу балалар!


Вячеслав ШИЛОВ





• • •

– Улым, тиздән мәктәпне тәмамлыйсың, сиңа һөнәр сайларга вакыт. Синең табиб булуыңны теләр идек.

– Син, нәрсә, әти! Мин бит чебенне дә үтерә алмыйм!

• • •

Сезнең бөтен нәрсәгез шоколадлы булуын телисезме? Бу бик гади эшләнә. Өч нәни малайга берәр плитка шоколад бирәсез дә аларны ун минутка үзләрен генә калдырасыз.



• • •

– Әниең күзләрендә беркайчан да яшь күренмәслек итеп яшә!

– Сериаллар каравын тыепмы?

• • •

Әнисе баласын йокларга яткыра:


– Нәнием, әгәр дә сиңа төнлә берәр нәрсә кирәк булса, «әни» дип кычкыр һәм әтиең шундук йөгереп килеп җитәр.

• • •

Кичен гаилә телевизор каршында утыра. Әнисе кызыннан сорый:

– Ә курчагың кайда?

– Мин аны йокларга яткырдым, чөнки бу фильмны балаларга карарга ярамый.



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Валерий ТАРАСЕНКО



Вячеслав ШИЛОВ

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Зарландыралар

Шундый заманалар җитте. Хәзер беркемгә бер сүз әйтеп булмый. Зарлана башласаң, транспорт йөртүче һәм кондукторлар:

– Гел әләкләп йөрсәгез, автобуссыз калырсыз. Җәяү атларсыз йә таксига утырырсыз.

Табиблар эшенә зарлансаң, алар:

– Күбрәк зарланыгыз. Табиблар да китеп барса, нишләрсез икән? Түләүлегә барырсыз!

Кибеттә:

– Гаеп табып йөрмәгез әле монда. Ите бозылган, сөте әчегән, имеш. Менә бөтенләй кибеткә ризык китерми башласалар, базарга барырсызмы? Югары бәядән, акцияләрсез алып карарсыз!

ЖЭУда:

– Сез әләкләүдән эшчеләр качып бетте. Сезгә һич ярап булмый: йә салкын өегездә, йә эссе. Карарбыз, кем эшләр икән сезгә шул барлы-юклы акчага?

Газ хезмәткәрләре:

– Сезгә ни җитми тагын?.. Зарланудан башка берни белмисез. Исегез киткән икән, техник хезмәт күрсәтү тиешенчә үтәлмәгән. Газ хезмәткәре килгәндер бит? Килгән! Бушка эшләп йөрибез бит инде.

Водоканалда:

– Һай, бу халыкның азынуы җитте. Исегез киткән икән, торбалардан су ага. Көтегез! Килмибез дип әйтмибез бит... Рәхәтләнегез яңа барлыкка килгән күл белән. Җәй, көннәр эссе. Барыгыз да диңгезләрдә ял итә алмыйсыз бит. Коенығыз рәхәтләнеп. Керләрегезне дә шунда юыгыз!

Мондый мисалларны күп китереп булыр иде. Кызганыч, тиешенчә хезмәт күрсәтмәсәләр дә, барысы да үз бәясен күтәрергә тырыша.

Хәбил ТУКМАНОВ

РЕФОРМАЛАР ЗАМАНЫ...

Бер-бер артлы реформалар
Бара илдә, күрәбез.
Бирәләр, малай, кирәкне –
Әле пока түзәбез.

Дару алырга дип керсә,
Кешенең исе китә:
Упаковкасына гына
Аның акчасы җитә...


Укытучы акчасына
Җитте дөрес карар чак:
"Укытучы көненә кал", – дип,
Дошманыңны каргар чак.

Подъездларда реформаны
Халык үзе ясады.
Хәзер күпләр бәдрәф эзләп
Читкә йөрми башлады.

Тели инде хакимият
Ил тормышын җайларга,
Тик, нигәдер, арта бара
Ярлылар да, байлар да...

Тормыш төрле: халык сине
Күмә кайчак рәхмәткә,
Ә кайвакыт ул җибәрә
Бик ерак "сәяхәткә"...

Сергей КОКАРЕВ



ШӘМГУН

Бездә дә шулай...

Баш редактор өстәлдәге пультның кнопкасына басып сорап куйды:

– Курәрченем, керт әле шул "Аккош" газетасы журналисты белән ике чокыр кофе!

Массакүләм чараларыннан килгән кыз урнашкан тынлыктан файдаланып алды. Блокнотына карап бирәсе сорауларын барлады, диктофонын әңгәмәдәше янына этеп кую өчен креслосын күчерде.

Ишек кинәт ачылып китте һәм аннан арты белән алга борылган – подносын ишеккә тидермәс өчен, сәркатип апа дисәң, картрак бугай, сиксән яшьләр тирәсендәге әби килеп керде. Сер бирми, житез кылана, әйтерсең лә гомер буе стюардесса яки официант булып эшләгән.

– Элек бик тә популяр ансамбльдәге биюче! – дип, горурланып карап куйды ул каршысындагы гаҗәпләнүчегә. – Элек җөмһүрият башлыгының да һушын алган биюче-солистка!

Кабинет хуҗасы подностан бер чокыр кофесын чөмереп куйды.

– Биючеләр бит утыз яшькә хәтле генә бииләр дә пенсиягә чыгалар. Ә болар кая барсын? Типографиягә урнашып, зур дәрәҗәләргә ирешеп, исеме Мактау тактасыннан төшмәгән, аннан соң безнең журналга чакыртылган, алдынгы хезмәт герое исеменә лаек булырдай кеше ул. Әле шул чакта Шәймиев белән төшкән фотосы да бар. Кем шундый хөрмәткә ирешкән әле? Андыйлар бик сирәк. Менә минем белән төшми бит әле килеп.

Шундый мактаулы сүзләр ишеткәч, әбиебез, шкаф янагына тотынып, пируэт ясап алды.

– Күрдеңме, чудо! – диде баш редактор мактанып. Татар биючеләре бер кырыйда торсын! Ул бит әле пианинода уйнаган кебек компьютерда текстлар баса, үзе әсәрләр яза!

Мондый сәркатипне каян табасың?.. Карагыз, пенсионер димәссең?!. Аңа умырып акча түләүле дә түгел. Җимертеп эшләсә дә... (Редактор пышылдауга күчте.) Хезмәт хакы – 15 мең, пенсиясе – 12. Бездә күп акча сораучы юк, шикаять язсалар, үз теләге белән дигән булып...

– Бездә дә шулай, – дип, журналист диктофонын сүндерде.

Рәшит МИНҺАҖ

ИКЕ ШИГЪРИ ФИКЕР

Кайвакытта бу түрәләр
Башкаларның куштаннарын
Җене сөйми,
Җирәнәләр;
Үзләренә куштанлансаң,
Хуҗам! – диеп һуштан язсаң,
Пәйгамбәргә әйләнәләр.

• • •

Байбичәләр мәҗлес җыя,
Берсен-берсе уздырып,
Бәйрәм китә бик кызып.
Берсе шуңа роман яза,
Икенчесе җыр чыгара:
Шайтан бии кызыгып.

Никифор ТУКМАЧЁВ

КАР-Р, КАР-Р, ЧИРИК-ЧИРИК...

Җәйләр үтеп көзләр җиткәч,
Үзгәреш җиле искәч,
Чыпчыклар сәхнә тоталар,
Былбыллар китеп беткәч.

Чиныйлар, ыңгырашалар
Бу дип, халык көйләре.
Халык җырларын имгәтте
Бу үзгәреш җилләре.

Кар-р-рагыз дип, канат кагып,
Алкышлыйлар каргалар:
Мондый тавыш, бу башкару
Әле тагын кайда бар?

Каргаларга моң кирәкми,
Булмады ни, булды ни.
Сәхнә генә буш тормасын
Чыпчык ни дә, Былбыл ни...



Рөстәм ЗАРИПОВ

ФОРСАТ

Төн уртасы, мин ут йотам, бетә дип СССР. Радиоалгыч тыңлаштырам, анда шытыр-пытыр... Бер дулкынга тарыйм, кемдер саф татарча сөйли, җепкә тезеп, бәйнә-бәйнә нәрсәнедер "төйи":

"Суверенитет! дип, тыштан, кылтаерга ярый. "Азатлык!" һәм "Бәйсезлек!" дип тырпаерга ярый; Кыйбатлатып сату аша,сосар өчен күпне,авылдан кысу мәслихәт, арзан хакка, сөтне! Төбәгеңдә миллионнан ашса чучка саны, чишмә суына тәм өстәр каты борын каны... Химия сәнәгатеннән файда тап һәр чатта, азу ярачак, әлбәттә, рак чире, як-якта... Һава бозып акча эшләү тапкырлыкка үрнәк; Сулышны акча киңәйтә булган саен күбрәк...

Фиргавен кабере төсле кәефханә корсаң, туташлар, "мисс" булабыз, дип, калыр бикиничан... Шәһидләр каны түгелгән изге чирәмлектә рок-музыка, җан өчен, – дин, сихәт кирәклектән... Сыра бәйрәмнәре кызык, эчеп күбенешле, сәрхуш кызлар, арт күрсәтеп рәткә тезелешле, мәчет дивары катында! Әйтелгәндә азан! Дөрләп янган чакта учак, кайнаганда Казан...

Катнаш никах та җиңде дип, Җиңү паркын ямьләп, тётя сыны торып басса, булырсың толерант! Әдәбиятта-сәнгатьтә чүп-чар китсен хутка, будалалыкка юллар ач, батыйльлекне котла... Синең өчен иң кулае милләт торсын бәйдә, катыга утырт син аны, йомшак итеп җәй дә...

Милләт аңын бутар өчен, тел җуйдыру аздыр, җырын чүп-чарга батырып, моңыннан да язып... Явыз Иван ныгытмасын төзекләндер, балкыт, безнең урамда бәйрәм, дип, канатлансын маңкорт... Зурла, иҗатчы санында йөргән йөзе юкны, утта янмый, суда батмый. Өстә йөзгән..."чук"ны, Ул баш ияр, тез йөгенер кушсаң, җырлар, биер. Тән сакчыңның күзе төшсә, кемнеңдер ур(ы)нына, берәр туганына төбәп яисә угълына, ул кемдер яшь әти булса, гаилә елында, ку син аны, селкетмичә кашыңның кылын да. Телен озайтса кем, сиңа, әйтмәсәм дә әйтим – Ирек ирегеннән язсын, хәкимлектән хәким... Күңелкәеңә килсә хуш, әгәр шундый кереш, "килешәм", дип аваз сал да, вазыйфаңа кереш!"

Җиде төн урталарында, байтак еллар элек, радиодулкын шундый "вәхи" китте җанга элеп. "Риза!" дип кычкырды гүя кайсыдыр, шар ярып... Ычкынды кулымнан шул мәл гүя алтын балык... Аннан янә шытыр-пытыр, элемтә югалды. Әллә тапшыру ноктасы тәмугка юл алды. Спектакль идеме ул, усал шаяртумы, бүгенгәчә сагышланам, аңлый алмый шуны... Колак кактыммы, үтүдән Форбс китабына, нәсел-нәсәпне ияртеп, кәс-кәс атлап кына...



Валерий ТАРАСЕНКО



Ринат АБЗАЛОВ



Валентин ДУБИНИН

Статистика

Айдар ФАРТОВ

Галәмәт зур супермаркет парковкасына кыйммәтле машинамны куйдым да китәр алдыннан тагын бер мәртәбә ягулык расходын күрсәткән укка күз төшердем. Иномаркамның багы туп-тулы. Шунда заправкадагы кыз белән сөйләшкәнемне искә төшердем.

– Сеңлем, ягулыкның бәясе күпме?

– Менә сиңа, исәнмесез! Соңгы атнада бензинның бәясе төште.

– Яхшы яңалык! Алай булгач, бакны тутырыгыз!

Мине шатлык биләп алды һәм яшәешемдә тынычлык хасил булды. Кесәмдәге акча янчыгымны капшап алдым, кабарып тора, памперс диярсең, елмаеп куйдым. Кибеткә керүем ашыйсы килүемне көчәйтте. Дүрт пакет җиләк-җимеш, ит һәм балык деликатеслары, сыр төрләре алу финанс күләмен киметмәде.

– Нишләп дүрт кенә пакет алдыгыз? – дип гаҗәпләнде кассадагы кыз. – Сез бит күбрәккә расчёт тотарга мөмкин?

– Әйе! Минем хезмәт хакым җитмеш өч мең!

– Ә безнең – кассирларныкы артыграк! – дип, исе китмичә озын керфекләрен лепердәтеп куйды ул.

Кызның дөресен әйтүе мине борчымады. Яшьләрнең уңышына мин шат кына.

– Башка эш эзләгез! – дип киңәш бирде ул.

– Аның каравы, мин күптән түгел генә яңа машина алдым, – дидем бераз төрттереп.

– Ә минем уникене балам була...

– Унике!

Мине сыйпап куйдылар. Мин йокы аралаш хатыныма карадым.

– Инде сәгать унбер. Иртәгә эшкә. Тагын йокың туймаган булыр. Телевизорыңны сүндер.

– Нәрсә? – экранга карадым.

– Халкыбызның хәле көннән-көн яхшыра. – дип сөйләп тора сакаллы аналитик. – Регионда уртача хезмәт хакы җитмеш өч мең, бу әле чик түгел! Шуның нәтиҗәсендә соңгы декадада җиңел машиналар сатылуы артты, фатирлар һәм зиннәтле әйберләр дә шулай. Чын күңелемнән әйтә алам: еллык инфляция кимеде, кызганыч, ике генә тиенгә бензин бәясе дә төште. Әмма кешеләр яхшырак ашый башлады. Бу яшьләрнең кәефләренә зур йогынты ясады, эш урыннарын сайлау мөмкинчелеге артты, гаилә кору теләкләре көчәйде, хатын-кызлар бала тудыра башлады – күпләп, күпләп, күпләп...

Мин кәефсез генә пультның кнопкасына бастым. Статистика программасы әкренләп сүнде.

– Их, – дип мыгырдандым хатыныма. – Нигә уяттың? Мин чын җәннәттә йөри идем бит!

– Иртәгә ныгыган рубль курсы турында сөйләячәкләр һәм дә туристик индустрия юнәлешләрен күрсәтәчәкләр. Курортка "очарсың", – дигән булды хатын, хәйләкәр генә елмаеп. – Мәрҗән утрауларына барырсың һәм диңгез һавасын сулап, исәрләнеп йөрерсең...

Руфия МИФТАХОВА

ЙӨЗ СҮЗГӘ СЫЙГАН ТОРМЫШ

Күз яше. Күкрәк. Бишек.
Сүз. Адым. Ыштан. Тишек.
Бакча. Комлык. Уенчык.
Күрше кызы. Алтынчык.

Мәктәп. "Бишле". "Икеле".
Туп. Футбол. ОГЭ. ЕГЭ.
Дус-иш. Тәмәке. Билән.
Җәй. Җиләк. Сыер. Печән.


Институт. Яз. Куаклар.
Кыш. Сессия. Койрыклар.
Сыра. Клуб. Кальян. Коньяк.
Диплом. Эш. Себер. Төньяк.


Кич. Йолдызлар. Мәхәббәт.
Иреннәр. Төн. Аһ, рәхәт.
Туй. Әби-бабай. Бакча.
Бәхәс. Талаш. Эш. Акча.

Бала. Бишек. Төн. Елаш.
Түшәк. Сөяркә. Талаш.
Эш. Гаилә. Гаилә һәм эш.
Җәй дә, көз дә, яз да кыш.

Ташкабак. Кыяр. Бакча.
Льгота. Пенсия. Мунча.
Туй. Кредит. Килен. Онык.
Ак чәчәкләр. Күзлек. Картлык.

Больница. Доктор. Йөрәк.
Сәдака. Кәфен. Зират.
Гайбәт. Гыйбрәт. Күз яше.
100 сүзгә сыйды кеше.





Абау!

ШӘХСИ ҮСМӘҮ

Мәскәү бизнесмены Анастасия интернетта блогер һәм тренер Надежда белән танышкан. Соңгысы шәхси үсеш тренинглары саткан, клиентларга «уңыш өчен башларын яңартырга» вәгъдә биргән. Анастасия өметле процесска кушылырга булган һәм 1 миллион сум акча түләгән. Әмма тренингтан соң бернинди үзгәрешләр дә күзәтелмәгән. Анастасия гуруга зарлану белән килгән, ләкин ул аңа хәзер 4 миллион сумлык бүтән тренинг алырга киңәш иткән. Ул аңа баерга булыша алмагач, Анастасиянең башы эшли башлаган һәм полициягә киткән.

БУЛМАГАН ЧИР

Кировтан килгән пар Тюмень пенсионерларында 12 миллион сум акча эшләгәннәр. Медицина үзәген оештыргач, медицина хезмәткәрләре, идарә итүчеләр һәм табиблар ролен башкарырга җирле халыкны эшкә алганнар, бушлай тикшерү өчен пенсионерларны эзли башлаганнар. Барысында да моңарчы күрелмәгән «авыру» булган, аны «клиникада» урнашкан могҗиза җайланма белән генә дәвалап булган, имеш. Процедура өчен 35 тән 110 мең сумга кадәр акча алганнар. Гомумән алганда, мошенниклар «аларны аякка бастырырга» һәм 127 олы яшьтәге Тюменьда яшәүчене алдауга ирешкәннәр.

БАШКАЛАРГА – ФӘН


Хәзер йорт чатларында сүгенү һәм гайбәт сөйләү нәтиҗәләре булырга мөмкин. Нижний Новгород өлкәсе суды, чатта яшәүчеләр арасында булган бәхәсләрдән соң, рәнҗетелгән күршеләргә компенсация түләргә һәм шул ук чатта ялган мәгълүматны кире кагарга карар чыгарган. Бу мисал – башкалар өчен фән. Хәзер рәнҗетелгәннәр әйтелгәннәрнең дөрес түгеллеген исбатларга тиеш түгел, ләкин хокук бозучы әхлакый зыянны капларга һәм җавап бирергә тиеш.

ОЧУЧЫ РЕЙДЕРЛАР


Новосибирск шәһәрендә яшәүче берәү өч көнгә генә өеннән киткән. Кайткач, ул өенең ярканатлар белән тулганын күргән. Аны бик пычрак фатирда 40 тан артык чакырылмаган кунак көткән. Очучы рейдерлар ачык тәрәзә аша очып кергән һәм шунда калырга булганнар. Баскынчылардан котылу өчен, хуҗага чиктән тыш чара күрергә туры килгән.











МОНЫ ҺӘРБЕР ТӨЗҮЧЕ БЕЛӘ...

- Монтаж күбеге юк икән – силикон тотыр.
- Чүкеч белән кагылган шөреп боргыч белән кертелгән кадакка караганда ныграк тора.
- Төзүчеләргә срокны мәңге итеп бирсәң дә, барыбер бераз кичектерүне сораячак.
- Алдан кисәтмәсәң, физика законнарын да бозып була.
- Заказчыга карусыз тәэсир итә торган тылсымлы сүзләр бар: «саран ике тапкыр түли», «төзелеш материаллары кыйбатлана», «сыйфат», «гарантия».





Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

ТИРЕС

Шул ук 90 нчы еллар. Алмаз Хәмзин туган ягы Түбән Кама районы Ташлык авылыннан Казанга кайтып килә. Үзенең "буханка" "УАЗ"игында. Машинаның салонында... тирес. Капчыкларда. Шәһәрдә бөтен нәрсә дефицит, бөтен нәрсә кыйбат. Шәһәр халкы яшелчә, җиләк-җимешне дачасында, бакчада үстерә. Хәмзин дә үзләренең Казандагы бакчаларын әнә шулай Түбән Кама тиресе белән туендыра. Капчык тирәсен чебеннәр сырып алган. Алар да Казанга кайта. "Буханка"ның шофёр ягы, тирес исе һәм чебеннәр комачауламасын өчен, яхшылап томаланган.

Мамадыш күперен чыгуга, бер гаишник туктата моны. Йөзенең һәр күзәнәгеннән татар икәне кычкырып торган егет честь биреп, үтә дә эре кыяфәт белән Хәмзингә эндәшә:

– Сиржант Хәмидуллин! Ышту визём?

Хәмзин нәрсә икәнен әйтә. Тирес дип түгел, авылчарак, кыскачарак, "б"га башланган өч хәрефле сүз белән генә. Сержантның кашлары җыерыла:

– Я не шучу! Ышту ыв салоне?

– Энекәш, – ди Хәмзин саф татарча. – Әйттем бит инде...

– Аткруй салун!

Хокук сакчысына буйсынмый чараң юк – ачып җибәрә Хәмзин машинаның ян ишеген. Ә анда... чыдап булмаслык ис! Ул гына түгел, саф һавага чыгуга аңгырайган чебеннәр күккә күтәреләсе урында, сержантның авыз-борын тирәсенә юл тота.

– Тфү! Тфү! – сержант чебеннәрне төкерә һәм каты гына итеп сүгенеп, ишекне ябып куя. – Фәләнеңне... Бар, абзый, юлыңда бул! Ычкын моннан!

Саф татарча әйтә ул соңгы сүзләрен.

ПРОТЕЗ

Алмаз Хәмзинның әтисе Наил абый сугыштан аяксыз кайта. Әмма ул үзенең гариплеген беркайчан да сиздерми. Алмазның Казанда укып йөргән студент чаклары. Әтисе аңа протез заводына кереп "аяк запасы" алып кайтырга куша.

Бара Алмаз протезга. Утыра чиратта. Янәшәдә җыен аксак-туксак. Бүлмәгә берәм-берәм чакырып кертәләр. Менә берзаман "Хәмзин!" дип кычкыралар. Керә. "Утыр!" – диләр. Утыра. Алмазга күтәрелеп караучы да юк. "Чишен!" – диләр. Трусикка хәтле чишенә. "Примеряйте!" дип, әтисенә дигән протезны китереп тоттыралар. "Ничек?" – ди Хәмзин, аптырап. Шул вакыт бүлмәдәгеләр гаҗәпләнүле карашларын Алмазга төби: "Хәмзинме?" – "Хәмзин!" – "Откуда у тебя нога?" – "Своя", – ди Алмаз.

Аңлашалар. Көлешәләр. Заказны калын кәгазькә төреп биреп җибәрәләр. Казан трамвайларында кайта-кайта кәгазьләр ертылып бетә, протез аякның балтыры белән табаны күренә башлый. Кешеләрнең күзләре шунда. Уңайсызланмый Алмаз, чөнки ул сугыш каһарманы – әтисе өчен аяк алып кайта!



– Син, әбекәй, чүкеч белән шәп эшлисең икән! Әйдә безгә, хезмәт дәресләре алып барырсың...

Эрнест ДЫШАЕВ, 1960 ел.



Борис СТАРЧИКОВ, 1960 ел.



Редактор эш вакытында.

Виктор ИГНАТЬЕВ, 1960 ел.



• • •

– Нәрсә, ак "Лексуста" килгән принцны көтәсезме?

– Юк... Иң кирәге: кешенең яхшылыгы. Ә "Лексус"ның нинди төстә булуы мөһим түгел.

• • •

– Сорау: үземә кытай машинасы сатып алдым, шуңа нинди яхшы запчастьлар куярга? Оригиналнымы, әллә башканымы?

– Бары оригинал кытай запчастьларын! Немец яки япон аналог-ясалмаларын сатып ала күрмә.

• • •

Көннәр буе бал корты кебек кем бик актив, үгез кебек гайрәтле, ат кебек тырыш һәм кичен эт сыман арып өенә кайта, шул мал духтыры белән киңәшләшергә тиеш, аның ишәк булып чыгу ихтималы бар.

• • •

Әбисе оныкчыгына әйтә:

– Өлкәннәрне тыңларга кирәк, әнә Красная Шапочка тыңламаган, шуңа күрә аны Соры Бүре ашаган.

– Дөресрәге, башта ул әбине ашаган!..

• • •

Ерак араларга йөрүче поездларның пассажирлары үзләрен өй мәчеләре итеп тоярга мөмкиннәр. Гел ятып торышлы, йоклыйсың, бернәрсә эшләмисең. Бары тик ашыйсың да, бәдрәфкә барып киләсең. Тагын тәрәзә аша кошларга карап уйланасың.

• • •

Гаилә кроссворд чишә. Хатыны:

– Хатын-кызга карап, ир кеше нәрсә тели? 4 хәреф.

Ире:

– Борщ.

– Юк, беренче хәреф һәм соңгысы "с".

– Соус.

– Кайчан да булса ашап туярсың микән син?!

• • •

– Кадерлем, син – минем тормышымның иң кирәге.

– Мескенем минем.

• • •

– Кешелек тарихында иң уңышлы карьераны кем ясаган?

– Маймыл!

– Ничек?

– Аңа Дарвин теориясе ярдәмендә кешелеккә чыгу мөмкинлеге барлыкка килгән.

• • •

Бер ир ресторанга керә, аңа меню китерәләр. Гаҗәпләнеп, официанттан сорый:

– Ни өчен менюда бәяләр күрсәтелмәгән?


– Ашыйсы килүегезне бозасы итмәдек!



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Николай ВОРОНЦОВ


Вячеслав ШИЛОВ





ӘКӘМ-ТӨКӘМ ТИЗЛЕГЕНДӘ

Хөрмәтле редакция! Менә инде ике ай буе безнең шәһәргә керү юлы ябык. Май ае уртасыннан бирле Башкала (Столичная) урамында юл киңәйтү эшләре башланган иде. Тантаналы ачу вакыты 15 июльгә билгеләнгән булса да, әлегә ремонт эшенең очы-кырые күренмәгән. Ә әйләнгеч юл Сәйдәш урамыннан, әмма ул машиналар агымының тыгыз булуына исәпләнмәгән. Казанда эшләүче шәһәрдәшләребезгә, әлеге эссе көннәрдә икешәр сәгать бөкедә утыру бик авырга туры килә.

Бу көннәрдә генә юлны төзеп бетерү вакытын тагын ике айга озайтканнары мәгълүм булды. Җаваплы түрәләр моны инженер корылмаларының катлаулы һәм аларны алыштыру кирәкле булуы белән аңлаталар. Шунысы игътибарга лаек: шул юлның кыска гына җире – проектның ике елын алып тора. Аның шулай буласын белгәч, җайлы гына әйләнгеч юлын да төзеп кую мөмкинлеге булгандыр бит? Озакламый килеп җитәчәк яңгырлы көз айларында нишләрсез?

Л. ГАРИЕВ

ЯШЕЛ ҮЗӘН

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ДИҢГЕЗ

Кадерле "Чаян"! Ремонт эшен пожар һәм су басу белән тиңлиләр. Кемгә ничек, ә менә безнең ишегалдында, мәсәлән, су басу ремонттан соң башланды. Яңалыкка без беренче яңгырга хәтле шатландык. Шунысы ачыкланды: башкаручылар мәктәп укучысына мәгълүм булган нәрсәне дә исәпкә алмаганнар.


Безнең йорт иңкүлектә салынган, искесе – яңгыр сулары агыза торганы зур иде, шуңа күрә нинди генә көчле яңгыр яумасын, су рәхәтләнеп акты. Ә хәзерге яңасы тегесеннән ике мәртәбә кечерәк икән. Норматив буенча, дип әйтәләр. Хәзер яңгыр яуган саен, бездә тездән югары дип әйтерлек диңгез барлыкка килә. Газоннарны, тротуарны, хәтта подъезд төбенә хәтле диңгез дулкыннары кага. Безнең шикаятьләргә игътибар бирүче дә юк. Ягъни аларга да диңгез тубыктан.

5/18 ГЭС бистәсендә яшәүчеләр

ЧАЛЛЫ



Виктор БОГОРАД



Валерий ТАРАСЕНКО

ДАМИР ГАРИФУЛЛИНга – 85 ЯШЬ



1939 елның 5 маенда Татарстан АССР Сарман районы Яхшыбай авылында күп балалы зур гаиләдә унберенче бала булып туган. Иске Кәшер урта мәктәбендә, Ключище техникумында, Казан университетында белем ала. 1958–1961 елларда – хәрби хезмәттә.

1957 елдан башлап – туган районында административ эштә.

1967–1970 елларда «Ленинчы» газетасының (Сарман районы) бүлек мөдире, 1995–1997 елларда «Сарман» газетасының мөхәррире, 1991–1995 елларда «Ватаным Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли.

1962 елдан башлап иҗат белән шөгыльләнә. Робагыйлар, балалар өчен шигырьләр яза. Район авыллары тарихы турында материаллар туплауга, шәҗәрәләр төзүгә, археография өлкәсендә зур көч куя.

«Казан утлары», «Гасырлар авазы», «Мәйдан» һ. б. журналларда 100 дән артык (Галимҗан Баруди, Шәйхелислам Хәмиди, Муллануp Вахитов, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай һ. б. турында) фәнни-тарихи, фәнни-популяр мәкаләләр бастыра.

Балалар өчен дүрт шигырь китабы, «Чыгарсыңмы каршы алырга», «Сарман районы энциклопедиясе», «Җырларым, шигырьләрем...», «Мең дә бер робагый» һ.б. китаплар авторы. 300 ләп җырның (шул исәптән, «Чыгарсыңмы каршы алырга?» В. Әхмәтшин көе) сүзләрен язган.

500 ләп шәҗәрә, шул исәптән, Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Минтимер Шәймиев, Рөстәм Миңнеханов, Фәрит Мөхәммәтшин, Бикчура ханның шәҗәрәләрен төзегән. Дин галиме Шәйхелислам Хәмиди, тарихчы Морад Рәмзи, мөгаллим һәм шагыйрь Кашшафетдин әс-Сөләеки кебек 130 асыл зат якташы турында «Илһамлы Сарман» китабында яза.

Дамир Гарифуллин Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Рафаил Төхфәтуллин, Сажидә Сөләйманова, Җамал Вәлиди исемендәге премияләр иясе. Сарманның мактаулы гражданы.

* * *

Безнең якның күрке зәңгәр таулар,
Киртләч ярлар, яшел аланнар...
Мондый җирне бүтән беркайчан да,
Беркайдан да инде табалмам.

Мондый җирдә хисләр канатлана,
Өмет ташлап китми бер сәгать.
Мондый җирдә борын салындырып
Кәеф төшерергә юк сәбәп.

Мондый җирдә яшәп туялмыйсың,
Сөеп туялмыйсың тормышны.
Мондый җирдә язны көткән кебек
Көтеп алу кирәк һәр кышны.

Мондый җирдә йөзгә җиткәндә дә
Яшәрәсең көннән көнендә.
Мондый җирдә күңел күкләрендә
Кояш кына көлә төнендә.

* * *

Минем аслым гади сүзләр аша
Шигырьләргә күчте, ахрысы.
Гамәл дәфтәрләрем урынына
Шигыремә баксын Тәңресе.

Нинди генә гөнаһ тапсалар да,
Ярлыкарлар мине, күрерләр, –
Ике дөньяда да кешеләргә
Мин әзермен җаным бирергә...

* * *

Гомер юлларыннан атлаганда
Икебезгә уртак юл салдык.
Кояш белән торып, яктылыкка,
Шау шатлыкка таба юл алдык.

Үлем сине миннән аерса да,
Йөрәгемдә уртак җыр калды;
Сагыш дөньясына чумганда да
Күңелем минем, күңелем җор калды.

Нинди матур көздә язмыш сине
Мәңгелеккә миннән аерды.
Елый-елый җилләр шашып исте,
Елый-елый күктә Ай йөрде.

Елый-елый очты ялгыз аккош,
Тавышлары җанны айкады.
Җырлап туймас йөрәгемне тәкъдир
Хәсрәт дәрьясында чайкады.

Ак каеннар кара күлмәк киеп
Кара күлгә кереп баралар.
Якынайган саен киң офыкка
Ерагая бара аралар.

Уртак юлны ялгыз дәвам итәм,
Һич тә белмим күпме барасын.
Тау артыннан Кояш чыгып килә,
Аяз күктә синең карашың...

Алга бара тормыш дигәннәре,
Тәгәридер шул ук күчәрдә.
Туктамыйча йөргән юлларыңда,
Сыктамыйча кирәк яшәргә...

ЧЫГАРСЫҢМЫ КАРШЫ АЛЫРГА?

Валерий ӘХМӘТШИН көе

Тыңларсыңмы яшьлек хисләремне,
Сарман көйләренә җырласам?
Каршы төшмәссеңме, йөрәгеңне
Мәхәббәтем белән чорнасам?

Минем белән тормыш сукмагыннан
Риза булырсыңмы үтәргә?
Аерылганда вәгъдә бирерсеңме
Кабат кайтуымны көтәргә?

Ашкынулы йөрәк көтә көн дә
Уртак таңның сызылып атканын.
Яшьлегемне җырга салган чакта
Кушылып җырларсыңмы, аппагым?

Кайткан чакта Сарман буйларына
Яннарыңда мәңге калырга,
Кырык эшең ташлап кырык якка,
Чыгарсыңмы каршы алырга?

ЯЛГЫЗЛЫКТАН КАЧЫП КАЛАЛМЫЙЛАР...

Ялгызлыктан качып калалмыйлар,
Бер таба ул адәм баласын.
Гомер иткән ярың китеп баргач,
Япа-ялгыз җирдә каласың.

Көннәр узган саен, йөрәкләргә
Тирәнрәк уела ярасы.
Матәм көне ерагайган саен,
Сагышларга бата барасың.

Ялгызлык ул айга-вайга куймый,
Җаныбызны сыный тоташтан.
Һәрбер гамәлебез үлгәннәрнең
Якты рухы белән тоташкан.

Яши-яши ялгыз торырга да
Өйрәтәдер тормыш дигәне;
Өйрәтәдер ялгыз күтәрергә
Иңебезгә язмыш өйгәнен.

Каплансаң да егылып, кирәк була
Күтәрелеп атлап китәргә,
Бергә чакның матур мизгелләрен
Онытмыйча саклап үтәргә.

Ялгыз башка яшәү җиңел диеп,
Бер юләре әйтмәс дөньяның.
Ача алмасам да шигыремдә,
Ни икәнен беләм мин аның.



Юныс ЗӨБӘЕРОВ

МИН ТАРТКАЧ

Гыйльман абзый күп еллар шахтада эшләгән кеше. Элекке заман булса, димәк, бай кеше дияр идек, хәзер әйтеп булмый.

Гыйльман абзый пенсиягә чыккач, хатыны белән авылга кайтып йорт сатып алдылар да тора башладылар. Шәһәрдәге фатиралары балаларына калды.

Авыл яшьләре шәһәр турында хыялланса, олы кешеләр авылны өстен күрә. Чынлап та, бер яктан, авылда тыныч. Трамвайлар дөбердәми, машиналар үкерми. Хулиганлык та ул чаклы түгел авылда. Авыл кешесендә, шәһәр кешеләре белән чагыштырып караганда, әхлаклык көчлерәк.

Әйтергә кирәк, йортның яхшысын сатып алдылар алар. Әйбәт кенә яшиләр, пенсиясе зур Гыйльман абзыйның, хатынынынкы да ару гына, авыл картлары пенсиясе белән чагыштырып булмый.

Тырыш кеше булып чыкты Гыйльман абзый. Умарта тота башлады. Уннан артык умартасы бар. Унлап сарык та асрыйлар. Шулай әйбәт кенә яшәп яталар.

Тик идиллия үк булып җитми тормышлары. Дөньяның бөтен ягы да әйбәт була алмыйдыр инде күрәсең. Бер ягы хатынына ошамый Гыйльман абзыйның. Гыйльман абзый күп тарта. Кайчан карасаң да, авызында тәмәке Гыйльман абзыйның.

Ә аның үпкәсендә бар. Күп шахтерлар кебек үк, ул да силикоз белән чирли. Бер ютәлли башласа, биш минутка сузыла. Җәлләп куясың үзен. Әллә нинди тавышлар чыгарып, буыла-буыла ютәлли.

Шуңа күрә дә инде Гыйльман абзыйның җәмәгате аның теңкәсенә тиеп бетә. Тартуыңы ташла да, тартуыңны ташла... Гыйльман абзыйның аңа җавабы әзер. “Москвада клиникада яткан идем. Бер бик белдекле, шуның өстенә Европада билегеле булган, профессор дәвалады. Шул миңа тарт, диде, тартмасаң үләсең, диде. Әйләнеп тә карамас идем тәмәкегә. Профессор кушкач, тартмый булмый”, – ди.

Ул үзенең тарту сәбәбен шулай дәрәҗәле кешенең киңәшенә сылтый. Хатыны бу сүзләрдән соң уйланып тора да бер сүз әйтми. Чынлап та профессор шулай кушкан микән дип уйлап куя куюын, тик сүз эндәшми. Медицина өлкәсендә бернәрсә белмәгән көйгә андый нечкәлекләргә кереп китеп булмый инде. Ничек үзеңне профессордан күбрәк белеп, тартма дисең...

Тик бер елны Гыйльман абзый чирләп китте дә аны башкаланың республика бүлнисенә салдылар. Гыйльман абзый торып йөри алмый, урында, хатыны да янында. Бүлниснең авыр чирлеләрне карарга персоналы җитми. Бервакыт болар янына палатага академик килеп керә. Чирлене академик үзе карарга булган. Җаен туры китереп, хатыны академиктан тарту мәсьәләсе турында да сораган.

– Ирем тартсынмы? – дигән.

– Юк, – дигән академик. – Категорик рәвештә тыям. Аның өчен тарту үзенә үзең кул салу кебек.

Шуннан хатыны көлеп җибәргән, тантаналы рәвештә иренең биш кап тәмәкесен чүп савытына ыргыткан.

Больницада ничек түзгәндер, әмма терелеп кайткач, Гыйльман абзый тагын тарта башлады. Башта хатыныннан яшереп тартты. Тик мондый эшне яшереп буламыни? Беркөнне хатыны ихатага чыкса, ире тарта. Моның тартканын күреп, хатыны чыелдап җибәргән:

– Академик аңлаешлы итеп әйтте бит сиңа. Нигә тартасың? Үләргә уйлыйсыңмыни вакытыннан алда. Яшәү туйдырдымыни? Ташла хәзер үк тәмәкеңне.

– Мин җир тетрәмәсен өчен тартам, тартмасам җир тетри, – дип җавап бирә Гыйльман абзый тыныч кына тавыш белән. – Җир тетрәве мөмкинлеге турында уйламасам, авызга да алмас идем тәмәкене.

– Нинди Җир тетрәве турында сөйлисең син, карт сантый? Бу якларда җир тетрәми бит, – дигән хатыны чиксез гаҗәпләнгән тавыш белән.

– Мин тарткач, – ди Гыйльман абзый тыныч кына. – Мин тарткач нишләп бу якларда җир тетрәсен? Әлбәттә, тетрәми.

Хәмид ВӘЛИДИ

ЯШЬ ГАИЛӘЛӘРГӘ БЕР СҮЗ

(киңәш йөзеннән)

– Хатының шул – үз абырганң,
Сөяркәнекеннән үзгә –
Кәкерерәк булган...
Турайтып мәтәшмә,
(сындыруың мөмкин)
Пырдымланса – дәшмә.
Эшең кытә, эшлә!

– Ирең үзеңнеке,
Теләсәң ни эшләт.
(җитмеш төрле һөнәре бар)
Бакырганчы иргә –
Те-лең-не тешлә.

Пычак йөзе – чар күргәчтен ачыла.
Хатын йөзе – ир күргәчтен ачыла.
Табын корганчы иреңнең
Күңел-рухын сыйла:
Сәламләш тә елмай,
Уйлап куяр: – Өйгә кергән, дип,
Тулган Ай!

Александр ШУЛЬПИНОВ





ЧАЯН
САТИРА һӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 8 (1945) август 2024
Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы,
Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылга алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан,
Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.08.2024 ел.
Тираж – 2000 Заказ А-1602
Редакциянең адресы: 420066,
Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

ЖЫРЧЫ МИРСӘЕТ ...
"БАС, ӘЙДӘ ..."
АЗИЯДӘГЕ ДӘҮЛӘТ
... АХУНОВ
ТУГАН ...
УРМАНДА БҮРЕ ...
НОТА
СЕБЕРДӘГЕ ЕЛГА
... БУЛУ (ТЫН КАЛУ)
"... ЕГЕТ"
"ЯШЬЛЕКТӘ СӨЙГӘН ..."
САМОЛЁТ
МИРСӘЙ ...
ӘХМӘТ ...
ДИҢГЕЗ ХАЙВАНЫ
"БИК САГЫНДЫМ ... БУЙЛАРЫН"
ШӘХСӘНӘМ ...
... КОЛӘХМӘТОВ
"ЯМЬЛЕ ... БУЙЛАРЫ"
"БӘДРӘ ..."
БАКЧА ЭШ КОРАЛЫ
... ЗӘКИЕВ ("ЧАЯН")
... КУЛЫМНЫ!
НОТА
АЙЛЫ ...
ЗУР МЕНДӘР, ТҮШӘК
«АЛТЫН ...» (ТУКАЙ)
ЧҮЛ ҖИРЕ
"... ПАРОХОД"
"ГОМЕР ..."
АШКАЗАНЫ ЭШЧӘНЛЕГЕН ЯХШЫРТУЧЫ ДАРУ
СЫЕР СӘЛАМЕ
... БИКТАҺИРОВ
БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЕ
АЛЬТЕРАЦИЯ БИЛГЕСЕ
ИСЛАМДА РУХИ БАШЛЫК
... КҮП
«ИДЕЛЕМ, ГЕЛ СИҢА ...»
(-1) ...
(-1) 1482 м
ЗӘҢГӘР ...
НОТА
... МАННАПОВ
НОТА
"ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН ..."



1. Акыллы һәм аңгыра кеше арасындагы аерма?

2. Түләүсез алынган сыр белән бушлай алынган дәвалану арасында нинди аерма бар?

3. Үрнәк булырлык гаилә бизнесына мисал?

4. Чишендерү уены ничек дип атала?

5. Алга таба ничек яшәргә белмәгәннәргә нишләргә?

6. Нәрсә ул экономия?

7. Хәзерге заманда бер-береңне яратып яшәү бурычы ничек тасвирлана?

ҖАВАПЛАР

1. Акыллылар ялгышлык ясарга тырышмый, ә аңгыралар үзләренең ялгышларын танымый. 2. Буш сыр тәбедә генә була, ә түләүсез дәвалану Конституциядә генә. 3. Ирнең – тату салоны, ә хатынның – татуировканы бетерү клиникасы. 4. Ипотека. 5. Якынрак яшәү. 6. Акчаны теләмичә генә туздыру ысулы. 7. Хатынның фотосурәтен социаль челтәрләрдә урнаштыру.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде


Чаянвордның чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 7 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«БЕР ГЕНӘ МИНУТКА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. ШӘЙДУЛЛИНА (Казан),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Апастан **Зәйнәп ЯРУЛЛИНА!**

Ринат АБЗАЛОВ



Ринат АБЗАЛОВка

Бар әле ул бездә фидакарьләр:
Журнал өчен янып яшәүчеләр!
Авырлыклар кичеп юлларында,
“Чаян”! – диеп байрак чөючеләр!
Шуларның син берсе, Ринат дустыбыз,
Армый-талмый иҗат итүчесе!
Яшәп, 70 кә үк җитүчесе!

Гомер бәйрәмең белән, коллегабыз!











4612750670080